2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, ГИК-экспертиза материалларын кушымталары белән Орган сайтында урнаштырганнан соң, 15 эш көненә туктатып торыла.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) Регламентның 2.5 пунктында санап кителгән документларның тулы комплектын тапшырмау, аларда тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр булу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен нигез булып торучы бер яисә берничә документның гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору;

3) документлар вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан тапшырылу яки имзалану;

4) мөрәҗәгать итүченең мәдәни мирас объектына карата хокуклары булмау, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең мәдәни мирас объекты хокук иясе яисә мәдәни мирас объектыннан файдаланучы мәнфәгатьләрендә эш итү хокукын раслый торган документларының булмавы;

5) мәдәни мирас объектларын саклау органынының экспертиза бәяләмәсе белән риза булмау, ул бу хакта заказчыга, килешмәүнең мотивлаштырылган сәбәпләрен күрсәтеп, язмача хәбәр итә. Ризасызлык сәбәпләренә түбәндәгеләр керә:

а) ГИК-экспертиза бәяләмәсен рәсмиләштергән көннән башлап 3 ел вакыт узу;

б) ГИК-экспертиза бәяләмәсе тәкъдим ителгән документлар буенча тискәре нәтиҗәләрне үз эченә ала;

в) экспертиза бәяләмәсен имзалаган экспертка карата түбәндәге шартлар ачыклау:

- заказчы (аның вазыйфаи заты яки хезмәткәре) белән туганлык элемтәләре булу [балалар, ир белән хатын һәм ата-аналары, тулысынча һәм тулысынча булмаган бертуган абый-энеләр һәм апа-сеңелләр (туганнан туган энеләр һәм сеңелләр), заказчының (аның вазыйфаи заты яки хезмәткәренең) ата-анасының икедән туган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре, тулысынча һәм тулысынча булмаган бертуган абый-энеләр, апа-сеңелләр (абыйлары һәм апалары)];

- заказчы белән хезмәт мөнәсәбәтләре булу;

- заказчы (аның вазыйфаи заты яисә хезмәткәре) алдында бурычы яисә башка мөлкәти йөкләмәләре булу, шулай ук заказчының (аның вазыйфаи заты яисә хезмәткәренең) эксперт алдында бурычы яисә башка мөлкәти йөкләмәләре булу;

- заказчының кыйммәтле кәгазьләренә, акцияләренә (устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләренә, пайларына) ия булуы;

- акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр яки мөлкәти хокуклар рәвешендә үзләре өчен яисә өченче затлар өчен файда алу максатында, тикшерү нәтиҗәләрендә яисә экспертиза бәяләмәсеннән килеп чыга торган карарда кызыксыну;

6) ГИК-экспертиза уздыруның билгеләнгән тәртибен бозу;

7) дөрес булмаган белешмәләрне үз эченә алган документларны экспертиза

